ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20 03 2023 г. № 55

2023 елның язгы чорында Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Төбәк яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яки вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, 2023 елның язгы чорында артык дымлануы аркасында килеп чыккан автомобиль юлларының конструктив элементлары ныклыгын тәэмин итү мөмкинлеге кимү белән бәйле рәвештә, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елның 1 апреленнән 30 апреленә кадәр Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүче, транспорт чарасы күчәренә туры килгән массасы 6 тоннадан артык булган йөкле яки йөксез транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертергә (алга таба – язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү).

2. Әлеге карарның 1 пункты көче түбәндәгеләргә карата җәелдерелми дип билгеләргә:

автобуслар белән пассажирлар ташу, шул исәптән халыкара;

азык-төлек продуктлары, хайваннар, авыл хуҗалыгы хайваннары һәм кошлары өчен азык һәм азык өстәмәләре, дару препаратлары, орлык фонды, ашламалар, почта һәм почта йөкләре ташу (әлеге абзацта күрсәтелмәгән йөкләр белән бергә ташудан тыш);

ягулык ташучы 16 тоннага кадәр йөк күтәрүчәнлектәге транспорт чаралары (бензин, дизель ягулыгы, судно ягулыгы, реактив двигательләр өчен ягулык, ягулык мазуты, газлы ягулык);

табигать афәтләре яки башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәкле йөкләр ташу;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәсе һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өчен җирле үзидарә органнары белән килешенү буенча Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлек нигезендә, юл-төзелеш һәм юл-эксплуатация техникасын һәм авария-торгызу һәм ремонт эшләре үткәргәндә кулланыла торган материалларны транспонировкалау;

федераль закон белән хәрби хезмәт каралган федераль башкарма хакимият органнарының транспорт чаралары;

каты коммуналь көнкүреш калдыкларын җыю һәм ташу өчен кулланыла торган махсуслаштырылган транспорт чаралары (чүп ташучылар).

3. «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесе, «Түбән Кама шәһәренең Бердәм заказчысы дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе, Түбән Кама шәһәре территориясендәге җаваплы оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә (оештырырга):

Россия Федерациясе законнары нигезендә, әлеге карарның 1 пункты белән билгеләнгән күчәренә туры килгән йөкләнеш иң чик рөхсәт ителгән йөкләнештән арткан йөкле яки йөксез транспорт чараларының Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча хәрәкәтенә вакытында махсус рөхсәт бирү;

Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларга мондый чикләүләрнең сәбәпләре һәм сроклары турында Интернет челтәрендәге сайтларда, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша вакытында хәбәр итү;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чорга Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган 8.20.1 һәм 8.20.2 «Транспорт чаралары арбасы тибы» өстәмә мәгълүмат билгеләре белән (табличка) 3.12 «Транспорт чарасы күчәренә туры килә торган массаны чикләү» юл билгеләрен урнаштыру.

4. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсенең Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлегенә транспорт чаралары хәрәкәте вакытлыча чикләнгән чорда юл хәрәкәте иминлеген үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә һәм үлчәү контроле постлары урнашкан урыннарда дежурлыкны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

5. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү бүлегенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары белән расланган төбәк яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яки вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибенең 9 пункты кысаларында, әлеге карар турында дәүләт контроль һәм күзәтчелек органнарына хәбәр итәргә.

6. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан

Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.К. Нәҗмиев

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881